ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«03» апрель 2024 ел Иске Абдул авылы № 07

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Торнаташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Иске Абдул авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Иске Абдул авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 14.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Иске Абдул авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Торнаташ авылын су белән тәэмин итү);»;

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электроматериаллар сатып алу, Торнаташ авылының урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 14 ноябрендәге 02 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Иске Абдул авылында гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Торнаташ авылын су белән тәэмин итү);»;

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электроматериаллар сатып алу, Торнаташ авылының урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иске Абдул авыл җирлеге, Торнаташ авылы, Мирная ур.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина